ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 апрель, 2018 ел № 24/8

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен караганнан соң, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 маддәләре нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 08 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 04 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 09 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 05 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16 санлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1) **3 нче маддәнең 2 нче өлешендә** «рекреация җирләре» сүзләрен «рекреация билгеләнешендәге җирләр» дип үзгәртергә;
2) **7 нче маддәнең 1 нче өлешендә** «җәмәгать тыңлаулары» сүзләрен «җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар» дип үзгәртергә;

3) **9 нчы маддәнең 1 нче өлешендә:**
– **5 нче пунктта** «муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары сакланышын тәэмин итү» сүзләренә «юл хәркәтен оештыру» сүзләрен өстәргә;
– **24 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«24) каты коммуналь калдыкларны туплау, җыю (шул исәптән, төрләре буенча аерым җыю), транспортта ташу, кабаттан эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;
– **25 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«25) шәһәрне төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, шәһәрне төзекләндерү эшләрен оештыру, шулай ук шәһәр урманнарын, шәһәр чикләрендәге аеруча саклانучы табигый территорияләрдәге урманнарны куллануны, саклауны, яңадан үстерүне оештыру;»;
– **33 нче пунктта** «(волонтерлык)» сүзен өстәргә;
4) **9.1 нче маддәнең 1 нче өлешендәге 13 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«13) федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү өчен шартлар тудыру, оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен ведомство оешмалары җитәкчелерeнең эшчәнлеген бәяләгәндә куллану һәм, федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәсендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү максатында чаралар күрүне контрольдә тоту;»;
5) **19 нчы маддәне түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:
«19 маддә. Җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар
1. Закон белән каралган очракларда муниципаль хокукый акт проектлары җәмәгать тыңлауларында яйсә иҗтимагый фикер алышуларда каралырга мөмкин.
2. Җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар халык, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, муниципаль берәмлек Башлыгы инициативасы буенча үткәрелергә мөмкин.
Халык яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы инициативасы буенча үткәрелүче җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан, муниципаль берәмлек Башлыгы инициативасы буенча үткәрелүче җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә.
3. Җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышу белгечләр, экспертлар, кызыксынган затларны чакырып үткәрелә.
4. Җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре рәсми бастырылырга (халыкка чыгарылырга) тиеш.

5. Җәмәгать тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Җәмәгать тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгеләүче муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив-хокукый актында җәмәгать тыңлауларының, иҗтимагый фикер алышуларның кайда һәм кайчан үткәрелүе турында халыкка алдан хәбәр итү, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан танышу, җәмәгать тыңлауларында, иҗтимагый фикер алышуларда шәһәр халкының катнашуын тәэмин итү, җәмәгать тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләрен, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезен кертеп, матбугатта бастыру (халыкка чыгару) чагылырга тиеш.»;

6) **28 нче маддәдә**

**– 1 нче өлешне** түбәндәге эчтәлектәге **11 нче пункт** белән тулыландырырга

«11) шәһәрне төзекләндерү кагыйдәләрен раслау.»;

**– 2 нче өлештә:**

**8 нче һәм 15 нче пунктларда** «җәмәгать тыңлаулары» сүзләреннән соң «иҗтимагый фикер алышулар» сүзләрен өстәргә;

**54 нче һәм 72 нче пунктларны** гамәлдән чыккан дип танырга;

7) **35 нче маддәнең 1 нче өлешендә:**

**6 нчы пунктта** «җәмәгать тыңлаулары» сүзләреннән соң «иҗтимагый фикер алышулар» сүзләрен өстәргә;

**8 нче һәм 9 нчы пунктларда** «җәмәгать тыңлаулары» сүзләреннән соң «иҗтимагый фикер алышулар» сүзләрен өстәргә;

8) **36 маддәне** түбәндәге эчтәлектәге **2.2 өлеше** белән тулыландырырга:

«2.2 Татарстан Республикасы Президентының шәһәр Хакиме вазыйфасыннан ваз кичү турындагы хокукый акты яки Шәһәр Советының шәһәр Хакимен отставкага җибәрү турындагы Карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Хаким, хокукый акт яки Карар белән ризалашмыйча, судка шикаять биргән очракта, суд Карары законлы көчкә ия булмыйча торып, Шәһәр Советы үз составындагы депутатлар арасыннан шәһәр Хакиме сайлау турында Карар кабул итү хокукына ия түгел»;

9) **41 нче маддәдә**:

**– 1нче өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Планлаштыру, бюджет һәп хисап өлкәсендә:

1) оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмалардан шәһәр бюджеты, шәһәр социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проктларын төзү өчен кирәкле мәгълүматлар таләп итү һәм җыю;

2) шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләү һәм гамәлгә кую;

3) шәһәрнең чыгымнар буенча йөкләмәләрен билгеләү һәм үтәү;

4) әлеге Уставка нигезләнеп, муниципаль бурыч белән идарә итү;

5) муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль алып торуларны, шул исәптән муниципаль берәмлек исеменнән кыйммәтле кәгазьләр чыгару һәм шәһәр бюджетына Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан кредитлар җәлеп итүне гамәлгә ашыру;
6) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше максатлары һәм приоритетлары белән килештереп, шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше һәм муниципаль идарәнең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү;
7) стратегик планлаштыруның җирле үзидарә вәкаләтләрендәге сорауларына караган документларны карау, раслау (хуплау) һәм гамәлгә кую;
8) җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларының мониторингын алып бару һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту;
9) стратегик планлаштыруның федераль законнар һәм муниципаль норматив-хокукый актлар белән билгеләнгән башка вәкаләтләре.»;
– **3 нче өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Әйләнә–тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларыннан файдалану өлкәсендә:
1) шәһәр чикләрендә әйләнә–тирә мохитне саклау буенча чаралар оештыру;
2) җир асты байлыкларын файдалануга биргәндә территория халкының социаль-икътисадый һәм экологик мәнфәгатьләрен үтәү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу;
3) гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгарганда, шулай ук файдалы казылмаларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануны һәм саклауны контрольдә тоту;
4) экологик экспертиза объектларын аерым территориядә реализацияләгән очракта һәм башка административ-территориаль берәмлекнең хуҗалык эшчәнлегендә, күздә тоткан башка эшчәнлектә әйләнә-тирә мохиткә тәэсире булган очракта, экологик экспертиза объектларына дәүләти экологик экспертиза комиссияләре утырышларында күзәтүче сыйфатында катнашу өчен экспертлар җибәрү;
5) үз вәкаләтләре чикләрендә, җәмәгать фикер алышулары, сорашулар, референдумнар нәтиҗәләре, экология оешмаларының (берләшмәләренең) һәм хәрәкәтләренең гаризалары нигезендә экологик экспертиза сораулары буенча карарлар кабул итү һәм тормышка ашыру;
6) экологик экспертиза үткәрелергә тиешле күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында халык арасында җәмәгать фикер алышулары, сорашулар, референдумнар уздыру;
7) халык таләбе буенча иҗтимагый экологик экспертизалар оештыру;

8) экологик экспертиза өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органнарына тиешле муниципаль берәмлек территориясендә күздә тотылган хуҗалык яисә башка эшчәнлек турында хәбәр итү;
9) прокуратура органнарына, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органнарына һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына экологик экспертиза объектын гамәлгә ашыру башлануы турында дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсеннән тыш хәбәр итү;»;
– **4 нче өлешне** түбәндәге эчтәлектәге **13.6, 13.7 пунктлары** белән тулыландырырга:
«13.6) җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез милек обьектларына хокукый затлар инициативасы белән территориянең комплекслы үсеше турында килешүләр төзү;
13.7) җирле үзидарә органы инициативасы белән территориянең комплекслы үсеше турында карар кабул итү;»;
– **8 нче өлешнең 8 нче пунктын** яңа редакциядә бәян итәргә:
«8) федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү өчен шартлар тудыру, оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен ведомство оешмалары җитәкчелеренең эшчәнлеген бәяләгәндә куллану һәм федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәсендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү максатында чаралар күрүне контрольдә тоту;»;
– **9 нчы өлешне**
түбәндәге эчтәлектәге **6.1, 6.2, 9.4.2, 11.2-11.4, 24.2-24.5** пунктлары белән тулыландырырга:
«6.1) күпфатирлы йортларның милек хуҗаларына капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары һәм капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулларын сайлау тәртибе турында мәгълүмат бирү;
6.2) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә кичектергесез капиталь ремонт үткәрү зарур булганда, бюджеты акчалары исәбеннән кире кайтару һәм (яки) кайтармау нигезендә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеге һәм тәртибен раслау;
9.4.2) бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы һәм җылылык энергиясен кулланучы арасында килешү төзегәндә, җылылык белән тәэмин итүнең сыйфат параметрлары һәм (яйсә) җылылык белән тәэмин итү бәясе зоналарында җылылык белән тәэмин итүдә рөхсәт ителгән өзеклекләрне чагылдыручы параметрлар буенча үзара аңлашылмаучылыкны карау, бәхәсләрне судка кадәр җайга салу һәм җылылык белән тәэмин итү килешүенә кертү өчен мондый параметрларның мәгънәсен билгеләү;
11.2) каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) булдыру һәм аларны карап тоту (Россия Федерациясе законнары белән мондый вазыйфалар башка затларга йөкләтелгән очраклардан тыш);

11.3) каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарын (мәйданчыкларын) урнаштыру схемасын билгеләү һәм каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын алып бару;
11.4) каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә экологик тәрбия алып бару һәм экологик культура формалаштыру.
24.2) гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру һәм мониторинг алып бару;
24.3) гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларында машина кую урыннары реестрын алып бару;
24.4) гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыручы техник чараларны урнаштыру, алыштыру, сүтү һәм карап тоту;
24.5) «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым законнарына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә тапшырылган башка вәкаләтләрне гамәлгә кую.»;
**9.7 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9.7) «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль закон белән билгеләнгән очракта, җылылык энергиясе чыганакларын, җылылык челтәрләрен эксплуатациядән ремонтка чыгаруны килештерү;»;
**11 нче пунктны түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:
«11) каты коммуналь калдыкларны туплау, җыю (шул исәптән, төрләре буенча аерым җыю), транспортта ташу, кабаттан эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;
**14 нче пунктны** түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:
«14) шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләр нигезендә шәһәр территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр урманнарын, шәһәр чикләрендә урнашкан аеруча саклануычы табигать территорияләрен куллануны, саклауны, яңадан торгызуны оештыру;»;
– **11 нче өлештә 10 нчы һәм 13 нче пунктларны** түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:
«10) «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм әйләнештә йөртү, этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль закон компетенцияләре кысаларында этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне сату өлкәсендә закон үтәлешен контрольдә тоту;
13) авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар булдыру, кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә теләктәшлек итү, социаль юнәлештәге коммерцияле булмаган оешмалар һәм ирекле ләр (волонтерлык) хәрәкәтенә теләктәшлек күрсәтү;»;
– **15 нче өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«15. Физкультура һәм спортны үстерү өлкәсендә:
1)җирле шартлар һәм мөмкинлекләрне исәпкә алып, физик культура һәм спорт үсешенең төп юнәлешләрен һәм бурычларын билгеләү, физик

культура һәм спорт үсеше буенча җирле программалар кабул итү һәм гамәлгә кую;
2) мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү;
3) «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль закон нигезендә спорт разрядлары һәм спорт судьялары квалификация категорияләрен бирү;
4) халыкның төрле катламнары арасында физик культураны һәм спортны популярлаштыру;
5) муниципаль рәсми физкультура һәм спорт чаралары үткәрүне оештыру, шулай ук гражданнарның яшәү урыннарында физкультура-спорт эшчәнлеген оештыру;
6) шәһәрнең физкультура һәм спорт чаралары календарь планын (ГТО нормалары комплексы буенча физкультура һәм спорт чараларын да кертеп) раслау һәм гамәлгә ашыру,;
7) шәһәрнең рәсми физкультура һәм спорт чараларында медицина ярдәме күрсәтүне тәэмин итү;
8) шәһәр территориясендә рәсми физкультура һәм спорт чаралары уздырганда җәмәгать тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүгә теләктәшлек итү;
9) муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә куелган һәм спорт юнәлешендә эшләүче оешмаларның Россия Федерациясе законнары нигезендәге федераль спорт стандарларына туры китереп эшләвен контрольдә тоту;
10) шәһәр җыелма командалары әзерлеген тәэмин итү өчен шартлар булдыру максатыннан балалар-яшүсмерләр спортын үстерү һәм спорт буенча Татарстан Республикасы җыелма командаларының спорт резервын әзерләүдә катнашу;
11) коммерцияле булмаган оешмаларга ГТО комлпексы нормативлары сынаулары (тестлары) үтәүне бәяләү хокукын бирү;
12) инвалидлар, сәламәтлеге чикле булган затлар өчен спорт һәм физик культура, адаптив спорт һәм адаптив физик культураны үстерүгә теләктәшлек күрсәтү;
13) «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль закон белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне тормышка;»;
10) **65 нче маддәнең 1 нче өлеше 2 нче пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) җирле бюджеттан бюджетара трансфертлар бирү тәртибен билгели;»;
11) **73 маддәдә:**
– **маддә исемен** түбәндәгечә үзгәртергә:
«73 маддә. Муниципаль программалар»;
– **2 нче өлешнең 3 нче абзацында** «ике ай» сүзләрен «өч ай» дип үзгәртергә;
– **4 нче өлешне** гамәлдән чыккан дип танырга;
12) **80 нче маддәне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«80 маддә. Шәһәр бюджеты средстволарын максатчан файдаланмау

Бюджет средстволарын бюджет турында карар, җыелма бюджет язмасы, бюджет язмасы, бюджет сметасы, килешү һәм күрсәтелгән средстволарны бирү өчен хокукый нигез булган башка документ белән каралган максатларга юнәлтү шәһәр бюджеты средстволарын максатчан файдаланмау дип таныла»;

13) **82 нче маддәнең 6 өлешендә 2 нче һәм 6 нчы пунктларын** гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевкә әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юнәлтергә.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев